Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең Кичкетаң торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2018ел, 25 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Кичкетаң авыл җирлегенең Кичкетаң торак пункты территориясендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   - гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау.
   - беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.
   - су белән тәэмин итүне оештыру.
   - күмү урыннарын карап тоту.
   - урамнарны яктыртуны оештыру.
   - Кичкетаң авылының ял паркын төзекләндерү.
   - Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту.
   - рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет рәисе З.Р. НУРИЕВ